КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 12 сентябрь г.Казань № 771

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 475 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 15 ноябрь, 936 нчы; 2013 ел, 10 июнь, 395 нче; 2013 ел, 2 ноябрь, 836 нчы; 2016 ел, 19 апрель, 239 нчы; 2017 ел, 28 июнь, 447 нче; 2019 ел, 30 апрель, 372 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1273 нче; 2020 ел, 28 гыйнвар, 41 нче; 2020 ел, 17 март, 193 нче; 2024 ел, 13 апрель, 253 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибенә, $4^1$ пунктның 4.1.3.1 пунктчасына «яшәү өчен» сүзләреннән соң «, шул исәптән» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сатулар үткәрмичә сатып алынулары гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренең яисә дәүләт милке чикләре билгеләнмәгән җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 11 июнь, 432 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 декабрь, 962 нче; 2018 ел, 12 октябрь, 920 нче; 2021 ел, 26 май, 370 нче; 2022 ел, 12 гыйнвар, 8 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Сатулар үткәрмичә сатып алынулары гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренең яисә дәүләт милке чикләре билгеләнмәгән җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибенә, 2 пунктның 6 пунктчасында «бакчачылык» сүзләре алдына «үз ихтыяҗлары өчен» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин